**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2021 ел **Чирмешән авылы** № 497

**2022 елга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы буенча муниципаль торак контроле кысаларында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалау программасын раслау турында**

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 ел, №248-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау программасын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында» 25.06.20021 ел, №990 карары, закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын комплексылы профилактикалау стандарты нигезендә һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законга, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы буенча муниципаль торак контроле кысаларында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалау программасын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин

Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитетының
17.12.2021 ел, № 497 карарына
1 нче кушымта

2022 елга Чирмешән муниципаль районы буенча муниципаль торак контроле кысаларында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау программасы

ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | 2022 елга Чирмешән муниципаль районы буенча муниципаль торак контроле кысаларында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау программасы |
| Программаны эшләүнең хокукый нигезләре | «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.202020 ел, №248-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүне профилактикалау программасын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында» 25.06.20021 ел, №990 карары, Закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын комплексны профилактикалау стандарты |
| Программаны эшләүче | Чирмешән муниципаль районы башкарма комитеты |
| Муниципаль контроль төре | Чирмешән муниципаль районында муниципаль торак контроле |
| Программа максатлары | Саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын булдырмау;<br>Контроль төрләре буенча мәҗбүри таләпләрне (мәҗбүри таләпләрне бозу санын киметү) бозуларны кисәтү;<br>Закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалау инфраструктурасын булдыру;<br>Закон тыңлаучы контрольдәге субъектларның өлешен арттыру;<br>Контроль-күзәтчелек эшчәнлеге системасының үтә күренмәлелеген арттыру;<br>Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян дәрәҗәсен киметү |

| | |
|---|---|
| Программа бурычлары | Законда саклана торган кыйммәтләргә зыян салуга һәм мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны ачыклау, аларның барлыкка килү куркынычын бетерү яисә киметү ысулларын билгеләү;<br>Закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян салуга һәм мәҗбүри таләпләрне бозуга китерергә мөмкин булган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерү;<br>Профилактик чараларның төрләренә, рәвешләренә һәм интенсивлыгына конкрет контрольдәге субъектларның (объектларның) үзенчәлекләренә һәм аларга бирелгән куркынычлык дәрәҗәсенә (куркыныч классына) бәйле булуын билгеләү һәм бәяләү, әлеге факторларны исәпкә алып, профилактик чаралар үткәрү;<br>Профилактика эшен оештыру өчен кирәкле статистик мәгълүматлар төрләре исемлеген билгеләү һәм җыю;<br>Муниципаль контроль органнары кадрлар составы квалификациясен күтәрү;<br>Контрольдә тотылырга тиешле субъектларга, шул исәптән заманча мәгълүмати-телекоммуникацион технологияләр кулланып, консультация бирү системасын булдыру. |
| Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | Программаны тормышка ашыру вакыты: 2022 ел. Чирмешән муниципаль районы буенча мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтүгә юнәлдерелгән профилактик чаралар планы нигезендә |
| Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты эшчәнлеген тиешле финанс елына финанслау кысаларында тормышка ашырыла. |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | Закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын киметү;<br>Законны тыңлаучы контрольдәге субъектлар өлешен арттыру<br>Муниципаль контроль органнары эшчәнлегенең үтә күренмәлелеген арттыру;<br>Контрольдә тотылырга тиешле субъектларга административ йөкләнешне киметү;<br>Контрольдә тотылган субъектларның хокукый грамоталылыгы дәрәҗәсен күтәрү;<br>Муниципаль контроль органнары вазыйфаи затларының квалификацияле профилактик эшен тәэмин итү;<br>Контрольдә торучы субъектларның намуслы үз-үзләрен тотышына мотивацияләү. |

| | |
|---|---|
| Программа структурасы | 1 бүлек. Контрольдә тотылырга тиешле өлкәнең торышын анализлау һәм бәяләү.<br>2 бүлек. Профилактик эшнең максатлары һәм бурычлары.<br>3 бүлек. Программа чаралары.<br>4 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү.<br>5 бүлек. Программаны тормышка ашыру механизмы<br>6 бүлек. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү. |

**1 бүлек. Контрольдә тотылырга тиешле өлкәнең торышын анализлау һәм бәяләү.**

Муниципаль контроль предметы булып Чирмешән муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып бару процессында юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлеше тора.

Контрольдә тоту чаралары муниципаль контроль органы җитәкчесе тарафыннан раслана торган еллык план нигезендә үткәрелә торган планлы тикшерүләр рәвешендә, шулай ук оешмалар һәм гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен законнар нигезендә үтәп планнан тыш тикшерүләр рәвешендә үткәрелә.

Узган чорда Чирмешән муниципаль районы буенча планлы, планнан тыш тикшерүләр үткәрелгән юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның гомуми саны:

| Чор | Берәмлек |
|---|---|
| 2019 | 0 |
| 2020 | 0 |
| 2021 (1 яртыеллык) | 0 |

Тикшерү барышында узган чор өчен Чирмешән муниципаль районы буенча хокук бозулар ачыкланган юридик затларның, шәхси эшкуарларның гомуми саны:

| Чор | Берәмлек |
|---|---|
| 2019 | 0 |
| 2020 | 0 |
| 2021 (1 яртыеллык) | 0 |

Узган чорда Чирмешән муниципаль районы буенча ачыкланган хокук бозулар фактлары буенча административ җәзалар салынган тикшерүләрнең гомуми саны:

| Чор | Берәмлек |
|---|---|
| 2019 | 0 |
| 2020- | 0 |
| 2021 (1яртыеллык) | 0 |

Узган чорда Чирмешән муниципаль районы буенча салынган административ штрафларның гомуми суммасы:

| Чор | Мең сум |
|---|---|
| 2019 | 0 |
| 2020 | 0 |
| 2021 (1яртыеллык) | 0 |

2019-2021 елның 1 яртыеллыгында хокук бозулар ачыкланмады.

Контрольдә тотылырга тиешле сфераның торышына контрольдә тотылырга тиешле субъектларның мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча мәгълүмати тәэмин ителешен яхшырту йогынты ясарга мөмкин һәм, нәтиҗә буларак, мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү.

Контроль астындагы өлкәдәге хәлне яхшыртуга җитәкчеләрнең һәм контрольдә торучы субъектларның хезмәткәрләренең хәбәрдарлык дәрәҗәсен күтәрү, шулай ук мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча үз вакытында чаралар күрү ярдәм итә ала.

Шуңа бәйле рәвештә, гамәлдәге таләпләр турында мәгълүмат бирү буенча аңлату эшләре алып барыла. Мәгълүмат Чирмешән муниципаль районы сайтында «Муниципаль контроль» бүлегендә урнаштырыла (https://cheremshan.tatarstan.ru/munitsipalniy-kontrol-3388517.htm).

## 2 бүлек. Профилактик эшнең максатлары һәм бурычлары.

Законнардагы мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау түбәндәге төп максатларга ирешүгә юнәлдерелгән оештыру, мәгълүмати, хокукый, социаль һәм башка характердагы чараларны муниципаль контроль органнары тарафыннан комплекслы гамәлгә ашырудан гыйбарәт:

Закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын булдырмау;

Контроль төрләре буенча мәҗбүри таләпләрне (мәҗбүри таләпләрне бозу санын киметү) бозуларны кисәтү;

Закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалау инфраструктурасын булдыру;

Закон тыңлаучы контрольдәге субъектлар өлешен арттыру;

Контроль-күзәтчелек эшчәнлеге системасының үтә күренмәлелеген арттыру;

Закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян күләмен киметү.

## 3 бүлек. Программа чаралары.

2022 елга Чирмешән муниципаль районы буенча
муниципаль торак контроле кысаларында мәҗбүри таләпләрне
бозуларны профилактикалау программасы

| № пп | Чара атамасы | Гамәлгә ашыру | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | вакыты | |
| 1 | Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру (https://cheremshan.tatarstan.ru/) муниципаль контрольнең һәр төре өчен мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар яисә аларның аерым өлешләре исемлеген, аларның үтәлешен бәяләү муниципаль контроль предметы булып тора, шулай ук тиешле норматив хокукый актлар текстлары | 2022 ел | Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру өчен вәкаләтле органнар (вазыйфаи затлар) |
| 2 | Мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча җитәкчелек эшләү һәм бастырып чыгару юлы белән, семинарлар һәм конференцияләр үткәрү, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре алып бару һәм башка ысуллар белән, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә мәгълүмат җиткерүне, консультацияләүне гамәлгә ашыру.<br>Мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта - гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләр, аларны гамәлгә кертү сроклары һәм тәртибе турында мәҗбүри таләпләрне билгеләүче яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге турында шәрехләмәләр, шулай ук мәҗбүри таләпләрне гамәлгә кертүгә һәм үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән кирәкле оештыру, техник чаралар үткәрү турында рекомендацияләр әзерләү һәм тарату. | | |
| 3 | Муниципаль контрольнең тиешле өлкәсендә гамәлгә ашыру тәҗрибәсен даими (елына бер тапкырдан да ким булмаган) гомумиләштерүне тәэмин итү. Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында тиешле гомумиләштерүләрне, шул исәптән мондый хокук бозуларга юл куймас өчен юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан күрелергә тиешле чаралар буенча киңәшләр белән мәҗбүри таләпләрне бозуның еш очрый торган очракларын күрсәтеп, урнаштыру | | |
| 4 | «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясындагы 5-7 өлешләре нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр бирү (әгәр башка тәртип федераль законда билгеләнмәгән булса) | | |

**4 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү.**

Программаны тормышка ашыру Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты эшчәнлеген тиешле финанс елына финанслау кысаларында тормышка ашырыла.

**5 бүлек. Программаны тормышка ашыру механизмы.**

Программаның координаторы - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары.

Программаның турыдан-туры башкаручылары булып Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар тора:

Муниципаль торак контроле - Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге.

Программа чараларын тормышка ашыру өчен Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар җаваплы.

Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар, хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, бер ел эчендә профилактика эше нәтиҗәләре турында хисап бирәләр.

Профилактик эш максатларына һәм нәтиҗәләренә ирешү өчен, шул исәптән Программаны гамәлгә ашыру һәм үз вакытында төзәтү максатларында, координатор программа чараларын тормышка ашыру дәрәҗәсенә мониторинг һәм бәя бирә.

**6 бүлек. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү.**

Закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау программасын тормышка ашыруның төп нәтиҗәсе булып 2022 елның гыйнварыннан алып 2022 елның декабренә кадәр муниципаль контроль төрләре буенча законнар таләпләрен бозу очракларының кимүе тора.

Профилактик чараларның файдалылыгын һәм нәтиҗәлелеген бәяләү түбәндәге индикатив күрсәткечләр буенча гамәлгә ашырыла:

- үткәрелгән профилактик чаралар саны, берәмлек;
- профилактик чаралар үткәрелгән контроль астындагы субъектлар саны, берәмлек.

| № п.п. | 2022 елга чара атамасы | Саны, берәмлек |
|---|---|---|
| 1 | Үткәрелгән профилактик чаралар саны | |
| 2 | Профилактик чаралар үткәрелгән контроль астындагы субъектлар саны | |